**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Керкәле авыл җирлеге**
**Керкәле авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 21 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге Керкәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, студентлар һәм ташламадан файдаланудан тыш, 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Керкәле авылы М. Җәлил урамнарындагы юлларны елешчә ремонтлау
- Керкәле авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Керкәле авылы, Совет урамында спорт мәйданчыгы

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Керкәле авылы, Советская урамы. 93 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Керкәле авыл җирлеге башлыгы Г.Х.Шириязданова